СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №29 (7212) | 12 март, 1991 ел. СИШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен.

### 17 март — Бөтенсоюз референдумы көне

## Октябрь казанышларын саклыйк

17 мартта үтәчәк Бөтенсоюз референдумы СССР халыклары өчен мөһим политик әһәмияткә ия. Шуңа күрә партия, совет органнары һәм җәмәгать оешмалары бу кампаниягә хәзерлек барышын үзагымга куя, игътибардан читтә калдыра алмыйлар. Референдум нәтиҗәләре бу мәсьәләдә аларның ничек эш алып баруына күп бәйле. Шуның өчен дә халык арасында хезмәт һәм торак урыны буенча да оештыру һәм аңлату эшләрен киң җәелдерү зарури.

Хәзер фикерләр плюрализмы һәм теләсә кем теләсә нинди тәкъдим, фикер белдерә ала. ТССР халык депутаты Ф. Бәйрәмова, мәсәлән, газета чыгышыннан күренгәнчә, республиканың ССР Союзы һәм РСФСРдан да аерылып чыгуы яклы. Аның бу идеясен төптән ялгыш саныйм, чөнки ул Балтыйк буе республикаларындагы кебек аяныч нәтиҗәләргә китерүе бик мөмкин. Әлбәттә, моңа юл куярга ярамый.

Без халыклар бердәмлеге белән көчлебез. Әнә шул бердәмлеге белән совет халкы бишьеллык планнарны срогыннан алда үтәп чыкты, илебезне индустриализацияләде. Бөек Ватан сугышында җиңеп чыкты. Сугыштан соңгы елларда халык хуҗалыгын торгызуда олысы һәм кечесе бердәм булып эшләде. Барысы Совет Социалистик Республикалар Союзы хезмәт сөючән халкының югары аңлылыгы аркасында гамәлгә ашырылды.

Мин 17 мартта барлык гражданнарны ССР Союзын һәм бердәмлекне саклап тавыш бирергә чакырам. Бүген илдә иҗтимагый кризис көчәя барганда без КПСС һәм хөкүмәт тирәсенә тагын да ныграк тупланырга, бөек акыл иясе В. И. Ленин җитәкчелегендә 1917 елгы Бөек Октябрь казанышларын саклап калу, бердәм демократик һәм яңартылган Союзны яклап тавыш бирергә чакырам.

**Н. САФИН,**
партия һәм сугыш ветераны. Норлат шәһәре.



**Таныш булыгыз: Норлат разведка бораулавы идарәсе токаре Владимир Николаевич Смирнов. Идарәдә 15 ел эшләү дәверендә хөрмәт һәм дәрәҗә казанырга өлгерде ул. Болар һәммәсе аңа намуслы хезмәт аша килде. Бүген Владимир Николаевичның рәсеме идарәнең Мактау тактасында тора.**

## Союзыбыз таркалмасын

Мин үзем сугыш ачысын күрмәсәм дә, сугышның нинди афәтләр китергәнен китаплардан укып, кинолардан карап беләм. Безнең халкыбыз ничә сугыш газабын башыннан кичергән, күпме кан койган, меңнәрчә ватандашларыбыз яу кырында ятып калган, тол аналар, ятим балалар күпме яшь түккән.

Хәзерге Кавказ арты республикаларында барган вакыйгаларны телевизордан карап, газеталардан укып хәйран каласың. Элек бер гаилә булып яшәгән азербайҗан белән әрмән, грузин белән осетин, үзбәк белән төрекмән сугыша, нәрсә җитми аларга?!

Билгеле, сугыш ачысын күргән, ачлыкны җилкәсендә татыганнары сугышмыйдыр.

«Симезлекне куй сарыгы гына күтәрә», ди үзбәк халкы. Бу бик дөрес һәм хак әйтелгән сүзләр, бик симерделәр бугай, рәхәткә түзми халык.

Кибет киштәләре буш, кияргә кием юк, ашарга ризык юк дибез. Урамнарда шәрә йөрүчеләр дә, ачлыктан егылып үлүчеләр дә күренми. Һәр йортка керсәң дә, нигъмәт, муллык. Тынычлыгыбыз, күкрәккә терәп кисәрлек икмәгебез бар, шуңа шөкер кылып яшисе иде. Бер сыныкка тилмереп яшәгән заманалар артта калды, алабута икмәген, крахмал ашаган көннәрен онытты халык. Һәр җирдә шулай бәрелешләр булып, милләтләргә таркалсак, илдә муллык булмаячагы билгеле. Әлегә кадәр барлык халкыбыз кулга-кул тотынып эшләде һәм яшәде.

Бердәм халкыбыз фашист Германиясен җиңде, рейхстагка җиңү байрагы кадады. Революция балкышы халкыбызны коллыктан азат итте. Бу уңышларга илебез тик милләтләр бердәмлеге аркасында гына ирешә алды. Хәзерге вакытта безнең районыбызда гына ничә милләт халкы яши, күпме катнаш гаиләләр бар, шушы милләтләр тату яшәгәндә генә районыбыз муллыкка ирешер. 1990 елга гына күз салсак та без моңа инанып идек. Үткән ел нинди авыр, явым-төшемле килде, шулай да районыбыз ашлык сату планын беренчеләрдән булып үтәде. Калган тармаклар буенча да намусыбыз саф безнең. Татарстанда гына да күпме хезмәт куеп үстергән игеннәрне ак карлар каплап китте. Бер өзлексез яуган яңгырлар безнең район территориясен генә читләтеп үтмәде бит. Барлык игеннәр җитәкчеләребезнең төпле фикерләве, тырышлыгы, халкыбызның аяусыз хезмәте, уңганлыгы аркасында җыеп алынды.

Әйдәгез, райондашларым, авылдашларым, киләчәктә дә бердәм булып кулга-кул тотынып эшлик, яшик, яңа үрләр яулыйк! Ялгыз яшәп кенә ил язмышын хәл итеп булмый. Союзны таркатмыйк. 17 мартта үткәреләчәк референдумга яңартылган Союзны саклап калу өчен бердәм булып «әйе» диеп тавыш бирик.

**Х. ШӘФИГУЛЛИНА.**
Фома авылы.

## Округ комиссиясендә

5 мартта Н. Х. Абдуллин рәислегендә СССР референдумының Октябрь комиссиясенең чираттагы утырышы булды. Анда Биккол, Фома, Кизләү һәм Норлат шәһәре участокларында 17 мартта тавыш бирүгә әзерлек эшенең барышы турында информация тыңланды. Әлеге мәсьәлә буенча И.Н. Мөбәрәкшин, Н. М. Кәлимуллина, С. Н. Вафин, В.Н. Ботрякова, Г. Н. Попин иптәшләр чыгыш ясадылар.

Комиссиядә исемлектә референдумда катнашырга хокукы булган 38 меңгә якын граждан теркәлүе билгеләнде. Бу көннәрдә участок комиссияләренә участокларны җиһазлау, исемлекләрне чагыштыру һәм тавыш бирү өчен таныклык тарату эшләрен төгәлләргә кирәк. Участокларда халыкка уңайлы сәгатьләрдә һәртөрле аңлатмалар һәм белешмәләр өчен комиссия членнарының дежур торуын оештыру зарур.

Комиссия утырышында шулай ук референдумны финанслау һәм тавыш бирү участокларын материаль-техник тәэмин итү белән бәйле мәсьәләләр каралды. Округ комиссиясе членнары СССР референдумының Үзәк Комиссияләреннән кергән документлар белән таныштылар.

Комиссия эшендә халык депутатларының Октябрь район Советы рәисе урынбасары Т. А. Назарова катнашты.

## Гражданнар игътибарына!

**2—11—65 номерын җыеп, районның һәм шәһәрнең һәр кешесе район Советы башкарма комитетының районның экономик һәм социаль үсеше белән идарә итүе һәм хезмәт күрсәтү сферасы, культура, сәламәтлек саклау һәм социаль тәэминат учреждениеләре эше мәсьәләләре буенча фикерләрен һәм тәкъдимнәрен әйтә ала.**

**Кергән замечаниеләр район Советының март аенда үтәчәк чираттагы сессиясенә әзерлек барышында анализланачак һәм файдаланылачак. Сессия халык депутатларының Октябрь район Советы башкарма комитетының 1990 ел өчен отчетын тикшерүгә багышланачак.**

## Тынычлыктан бары башлана

**Мин фронтовик, 70 яшемә җиткәч беренче тапкыр кулыма каләм алырга булдым. Үзем урын өстендә ятам, радио тыңлый һәм телевизор гына карый алам. Илебездә катлаулы хәл килеп туды. Хәзер, кем әйтмешли, тамаклар тук, әмма тынычлык юк. РСФСР Югары Советы рәисе Б. Н. Ельцинның 19 февральдәге чыгышы моңа ачык дәлил. Һәм, әйтергә кирәк, ул чыгыш мине тетрәндерде. Ул илебезне таркату юлына басты. Бу мәсьәләдә минем фикер бәхәссез: ач-ялангач булган чакта илебезнең бердәмлеген саклаганны бүген таркатуга юл куймабыз.**

**Ил язмышын хәл итү буенча үткәрелә торган референдум уңаеннан Х. Х. Морадыймовның 23 февральдәге интервьюсы белән дә кызыксынып таныштым. Аның фикерләре белән тулысынча килешәм. Аерым союздаш, шул исәптән Балтыйк буе республикалары лидерлары һәм парламентлары илне таркатуга юнәлдерелгән курсны гамәлгә ашыралар. Әммa безгә моңа юл куярга ярамый, ил бердәмлеге өчен ахыр чиккәчә көрәшергә кирәк. Халыклар арасында бердәмлек һәм тынычлык сакланганда гына көчле дәүләт бит без.**

**А. КРАСНОВА.**
Сәләнгеш авылы.

### Ачынып язган хатлар

## Яңа мәктәп кайчан төзелер?

Мине, күпчелек ата-аналар кебек үк, балаларны укыту проблемасы борчый. Шәһәрдәге район мәгариф бүлегенә караган 4 урта мәктәпнең берсендә генә бер сменада укыталар. Шәһәр үсә, мәктәп балаларының саны арта. Аларның күбесе икенче сменада укый, мәктәптән соң кайта.

Шәһәрдә яңа мәктәпнең зарурилыгы көн кебек ачык. Бу хакта сүз дә алып барыла, тик әлегә эш шуннан ары киткәне юк. Халык депутатларының шәһәр Советы, район халык мәгарифе бүлеге бу мәсьәлә хакында газета аша җавап бирсә иде?

**Ф. САФИУЛЛИНА.**

## Бәяне кем билгели?

Күпме еллар аракы кытлыгыннан соң кибетләрдә «Портвейн молдавский» пәйда булды. Талонсыз, иркле сатуда. Килешү бәясе нигезендә сатыла, 3 литрлы банкасы 51 сум 60 тиен.

Мине бер нәрсә кызыксындыра: шундый кыйммәт бәяне кем кем белән килешеп куйган икән? Райпо җитәкчеләре шушы сорауга җавап бирерләр бәлки. Бу сорау башка газета укучыларны да кызыксындырадыр, югыйсә?....

**А. НИКИТИН.**
**Норлат шәһәре.**

## Мактаулы исем

Автомобиль транспорты өлкәсендәге хезмәтләре өчен Норлат-Октябрь автотранспорт предприятиесе шоферы Вениамин Анатольевич Зайцевка ТССР Югары Советы Президиумы Указы нигезендә «Татарстан ССРның атказанган транспорт хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

### Бүгенге санда

*17 МАРТ—РЕФЕРЕНДУМ КӨНЕ
*ССР СОЮЗЫН САКЛАУ ТУРЫНДА
*БЕЗНЕҢ РЕЙД.
*СЕССИЯГӘ ХӘЗЕРЛЕК

